# Гәрафәт көне

# يوم عرفة
## اللغة التترية

ALSARHAAN.CON

عرفة ذلك يوم المشهود

Гәрафәт көне – истәлекле көн.

مع طلوع الشمس يوم التاسع من ذي الحجة يتجهم الحجاج الي عرفة، لأداء ركن الحج الأعظم، في يوم من الأيام العظيمة المشهودة التي أقسم الله تعالي بها لفضلها و علو قدرها و شرفها،

Зөл-хиҗҗә аеның тугызынчы көнендә кояш чыкканнан соң хаҗ кылучылар иң бөек хаҗ нигезен үтәр өчен гәрафәткә юл тоталар. Бу көн бөек әһәмиятле, фазыйләтле һәм шәрәфле булу сәбәпле Аллаһ аның белән ант итеп әйтә:

قال تعالي: "وَالْيَوْمِ الْمَوْعُودِ وَشَاهِدٍ وَمَشْهُودٍ". البروج ٢-٣.

"Вәгъдә ителгән көн белән һәм шәһадәт китерүче һәм раслаучы белән ант итәм". (Буруҗ сүрәсе 2-3 аятьләр).

فاليوم المشهود، هو يوم عرفة. كما جاء ذلك عن النبي صلى الله عليه وسلم.

Һәм Пәйгамбәребездән ﷺ килгәнчә, раслаучы көн –ул гәрафәт көне.

و من فضل هذا اليوم علي سائر الأيام، أنه يوم الذي أخذ الله فيه الميثاق علي بنى آدم.

**Башка көннәр белән чагыштырганда шушы көннең фазыйләте – бу көнне Аллаһ Адәм балаларыннан шартнамә алган.**

و اليوم الذي أكمل الله فيه الدين و أتم فيه النعمة على النبي صلى الله عليه وسلم و أمته،

**Һәм шулай ук Аллаһ динне тәмамлаган һәм Пәйгамбәребезгә ﷺ һәм Аның өммәтенә нигъмәтләрен тулыландырган көн.**

و هو يوم مغفرة الذنوب و العتق من النيران.

**Һәм гөнаһлар кичерелеп уттан азат ителә торган көн.**

و هو يوم مغفرة الذنوب و العتق من النيران.

**Һәм гөнаһлар кичерелеп уттан азат ителә торган көн.**

و هو يوم العيد لأهل الموقف بعرفة.

**Шулай ук Гәрафәттә торганнар өчен бу бәйрәм көне.**

شرع النبي صلى الله عليه وسلم صيامه لغير الحاج

**Пәйгамбәребез ﷺ хажда булмаучылар өчен шушы көндә ураза тотуны раслаган.**

وِ قال: "صِيَامُ يَوْمِ عَرَفَةَ، أَحْتَسِبُ عَلَى اللهِ أَنْ يُكَفِّرَ السَّنَةَ الَتِي قَبْلَهُ، وَالسَنَةَ الَتِي بَعْدَهُ»، أخرجه

**Пәйгамбәребез ﷺ: "Гәрафәт көнендә тотылган ураза сәбәпле аннан алдагы елның һәм аннан соң буласы елның гөнаһлары кичерелер дип Аллаһка өметләнәм"- дип әйтте**

و على عرفة يقف الحجج ذاكرين الله تعالى، متوجهين إليه بالدعاء، خاشعين متبرعين حتي غروب الشمس، يباهي الله تعالى بهم ملائكته عشية ذلك اليوم.

**Һәм шушы көнне хаҗ кылучылар тыйнаклык һәм басынкылык белән Аллаһны искә алып, Аңа дога белән мөрәҗәгать итеп, кояш батканчыга кадәр Гәрафәттә торалар.**

قالِ النبيِ صلىِ الله عليه وسلمِ : "خَيْرُ الدُّعَاءِ دُعَاءُ يَوْمِ عَرَفَةَ، وَخَيْرُ ما قُلْتُ أَنَا وَالنَّبِيُّونَ مِنْ قَبْلِي: لَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ، وَلَهُ الْحَمْدُ، وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ»

( رواه

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: " Иң яхшы дога – ул Гәрафәт көнендә кылынган дога, һәм мин һәм миңа кадәр булган пәйгамбәрләр әйткән иң хәерле сүзләр – ул "Лә иләһә илләЛлаһ, ләһү вәхдәһү лә шәрикә ләһ, ләһүл-мүлк үә ләһүл-хәмд, үә һүвә гәлә күлли шәйин кадир"".